*Мөслим гимназиясе укучылары газетасы*

МӨСЛИМ ГИМНАЗИЯСЕ

# ТЫЛСЫМ+

4 (51)

Гыйнвар, 2023 нче ел

2023 РОССИЯДӘ УКЫТУЧЫЛАР ҺӘМ ОСТАЗЛАР ЕЛЫ

2023 ГОД НАЦИОНАЛЬНЫХ КУЛЬТУР И ТРАДИЦИЙ МИЛЛИ МӘДӘНИЯТЛӘР ҺӘМ ГОРЕФ-ГАДӘТЛӘР ЕЛЫ

**Бу санда**

*Тату сыйныф серләре* 2

*Уңышларыбыз сөендерә* 2

*Кулларда балалар язмышы – булмасын аларның ялгышы* 3

*Саулыкны сатып алып булмый* 3

*Укучылар иҗаты* 4

## ГИМНАЗИЯ СУЛЫШЫ

### ХӘЕРЛЕ СӘГАТЬТӘ!

2023

Яңа – 2023 елга аяк бастык бит, дуслар! Сез әле, бәлки, игътибар да итмисездер, әмма дә ләкин... еллар шул кадәр тиз үтә икән ул. Менә генә яңа елны башлыйсың, көндәлек мәшәкатьләр, ыгы-зыгылар, сезнең очракта – дәресләр, бишлеләр, олимпиадалар, каникуллар, дуслашулар һәм үпкәләшүләр белән ел азагы килә дә җитә.

Шуңа күрә, беләсезме, ни теләр идем мин сезгә? Һәр көннең, сәгатьнең кадерен белүегезне. Моның исә бик гади ысулы бар – план төзедегезме әле? Ә айлыкны? Атналыкны? Ай-ай-ай, куңелсез булыр ул план буенча яшәү, дияргә ашыкмагыз. Планга башкарасы эшләрне генә түгел, ялны да кертергә кирәк, дип саный бит әнә психологлар. Димәк, безнең тормыш нәтиҗәле дә, күңелле дә булырга тиеш!

### ЕЛ УКУЧЫСЫ –2022



Башлангыч сыйныф укучылары арасында сәләтле балалаларны ачыклау, һәрьяклап үсеш алган шәхес тәрбияләүдә нәтиҗәлелеккә ирешкән мөгаллимнәрне барлау максатында “Ел укучысы – 2022” бәйгесенең финал этабы үтте.

Әлеге бәйгедә 4 нче б сыйныфы укучылары җиңү яулады: Закиров Искәндәр - җиңүче, 1 нче урында Бариев Ислам, 2 нче урында Мөҗипов Әмир, “Тапкырлык өчен” номинациясендә Габидинов Гадел. Укытучылары Ләйсән Әхмәтгаяновнаны, җиңү яулаган укучыларны зур уңышларга ирешүләре белән котлыйбыз!

### ФӘН ОЛИМПИАДАСЫ КӨНДӘЛЕГЕ













2023 елның 9 нчы гыйнварыннан Татарстан Республикасы укучылары өчен 24 фән буенча Бөтенроссия олимпиадасының төбәк этабы старт алды.

Укучылар өчен уздырыла торган фән олимпиадаларының рәсәй һәм республикакүләм турында Мөслим гимназиясе укучылары да катнаша. Куанырлык нәтиҗәләр дә бар.

10 сыйныф укучысы Зиннуров Илдар район данын яклап, математика фәне буенча "Олимпка юл" республика олимпиадасының йомгаклау этабында призлы урынга лаек булды. Укытучысы Асылгараева Гөлүсә Әскать кызы.

Рус теле буенча 10 нчы сыйныф укучысы Зиннуров Илдар (укытучысы - Хәйруллина Чулпан Алмаз кызы), 9 нчы а сыйныфы укучылары Сөләйманова Диана, Авзалова Нәргизә (укытучылары - Галиева Ирина Тимерхан кызы), 11 нче сыйныф укучысы Эльвина Фатхуллина (укытучысы - Юлдашев Илдар Наил улы) тарих фәненнән региональ этабы призерлары булдылар. Укучыларны һәм укытучыларны зур уңышлары белән тәбрик итәбез! Уңышлар дәвамлы булсын!

## ТАТУ СЫЙНЫФ СЕРЛӘРЕ





“Тату сыйныф серләре” республика конкурсы ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы инициативасы белән үткәрелә.

Мөслим районы мәктәпләре арасында ата-аналар комитетларының “Тату сыйныф серләре” республика бәйгесенең муниципаль этабы узды.

Әлеге бәйгенең максаты балаларны тәрбияләүдә белем бирү оешмалары һәм ата-аналар бердәм булып эшләгән иң яхшы коллективны барлау, аларны башкаларга үрнәк итеп күрсәтү, популярлаштырудан гыйбарәт.

Гимназиянең 6 нчы б сыйныфының ата-аналар комитеты, 17 команда арасында, муниципаль этабта беренче урынны яулады һәм зона этабында катнашу хокукына ия булды.

28 гыйнварда Минзәлә район мәдәният йортында "Тату сыйныф серләре" конкурсының зона этабы узды. Конкурста Актаныш, Сарман, Минзәлә, Тукай районнарының ата-аналар комитетлары командалары да катнашты. Безнең бердәм команда жюри хөкеменә визитка, иҗади проект һәм класс интернет-ресурсын тәкъдим итте. Мөслим гимназиясенең 6 нчы б классны ата-аналар комитеты зона этабында да җиңүче булды.

6 нчы б сыйныфы укучыларын, сыйныф җитәкчеләре Хәйруллина Чулпан Алмаз кызын уңышлары белән котлыйбыз!

## УҢЫШЛАРЫБЫЗ СӨЕНДЕРӘ

### Аралашу марафоны




«Сферум» мәгълүмати-коммуникацион белем бирү платформасы, декабрь аена нәтиҗә ясап, «Аралашу марафоны» акциясендә җиңүчеләрне игълан итте. Гимназия коллективы һәм укучылар Сферум платформасында актив аралашып, Россия Федерациясе буенча җиңүгә ирешеп, ноутбук алу хокукын яуладылар.

А.Р.Шәрифуллин, Г.И.Мөхәммәтҗанова, И.Т.Галиева смартфонга ия булдылар. Аларны, гимназия коллективын зур җиңүгә ирешүебез белән котлыйбыз!

### "Солдатка хат" акциясе



"Солдатка хат" акциясен РФ Оборона һәм Мәгариф министрлыклары ярдәмендә "Яшь армия" хәрәкәте гамәлгә ашыра. Украинада махсус операция уздыру вакытында дистәләгән мең ватандашыбызга - үз бурычларын мактаулы башкаручы Россия сугышчыларына хат-хәбәрләр барып ирешә.

Мөслим гимназиясе укучылары да "Солдатка хат" акциясенә кушылып, Украинада махсус операцияләрдә катнашучы хәрбиләргә күңел күтәргеч һәм рухландыргыч хатлар яздылар. Хәрби кыр почтасының барлык юлламалары, һичшиксез, үз адресатларын табачак.

### Театр - яктылыкка, нурга илтә



Балаларның сәнгать һәм эстетик культурасын үстерү,тормышта яхшылык һәм матурлыкны күрергә өйрәтү максатыннан, “Мөслим егете, Мөслим кызы” проекты кысаларында, гимназиянең актлар залында һәр сыйныф театр әзерләп гимназия тамашачысына тәкъдим итә. Нәни артистлар рольгә кереп, бик матур итеп чыгыш ясыйлар. Сәхнә бизәлеше, костюмнар да үз югарылыгында. Башлангыч сыйныф укучылары башлап җибәргән эстафетаны гыйнвар, февраль айларында калган сыйныфлар да дәвам итәр дигән өметтә калабыз.

### Искиткеч вожатый



Балалар иҗтимагый хәрәкәтенең ролен аңлату, отряд вожатыйларының дәрәҗәсен күтәрү, педагог профессиясенә кызыксыну уяту максатыннан “Искиткеч вожатый” конкурсының муниципаль туры уздырылды. Киеренке ярыштан соң, гимназиянең 10 нчы сыйныф укучысы Минһаҗева Диләрә икенче урынга лаек булды.

## КУЛЛАРДА БАЛАЛАР ЯЗМЫШЫ – БУЛМАСЫН АЛАРНЫҢ ЯЛГЫШЫ!

### Тәртип сагында



Җәмгыятьтә барган тискәре күренешләр яшь буынны да бик авыр социаль-психологик ситуацияләрдә калдыра. Балалар һәм яшүсмерләр күп вакыт аларны җиңеп чыгарга әзер түгел һәм бу – тискәре нәтиҗәләргә китерә. Хокук бозуларны кисәтү, җинаятьләрне кисәтү айлыклары районыбызда ел саен үткәрелә. Безнең гимназия дә бу айлыкларны үткәрүдән читтә калмый. Гимназиянең беренче категорияле социаль-педагогы Әмирова Миләүшә Рөстәм кызына, шул турыда таныштыру максатыннан, берничә сорау белән мөрәҗәгать иттек.

***Миләүшә Рөстәмовна, үзегезнең эш белән бераз таныштырып китсәгез иде?***

Тискәре күренешләрне булдырмас өчен, без – педагоглар алдына төрле социаль-актив позицияле, тискәре күренешләргә: «Юк!» – дип кистереп әйтә белүче, үтемле сүзе белән башкаларга да ярдәм итә алучы шәхес тәрбияләү бурычы куела. Бу шәхес сәламәт тормыш рәвеше алып барырга һәм яхшы белем алып, киләчәктә үзенең урынын табарга тиеш. Хокук бозуны кисәтү эшенең төп үзенчәлеге – башлангыч профилактика уздыру.

Социаль-педагог буларак, хокук бозуларга карата төрле профилактик чаралар үткәрергә тырышам. Укучылар белән төрле эш алымнары кулланам: рәсем, плакатлар ясау, инша язулар, әзер презентацияләр алып килү, төрле белгечләр белән очрашулар үткәрәм. Бу алымнар исә укучыларның сәламәтлеген ныгытырга булыша, кешелеклелек сыйфатларын арттыра, яшүсмерләргә кече яштән сәламәтлекне сакларга, ныгытырга булыша.

***Гимназиядә хокук бозуларны кисәтү максатыннан нинди чаралар оештырыла?***

Мәктәбебездә хокук бозуларны кисәтү максатыннан профилактик отряд эшләп килә. Уку елы башында план төзелә, һәр ай саен төрле профилактик чаралар үткәрелә, хокук бозуларны кисәтү советы булдырылды. Еллык эш планыннан чыгып, «Законнарны беләсеңме?», «Минем хокукларым һәм бурычларым» дигән темаларга сыйныф сәгатьләре, начар гадәтләргә каршы «Тәмәке белән бергә тартучы да яна», «Наркотиклар – тормышны җимерүче», «Алкоголизм гомерне кыскарта», «Наркомания – кешелек дошманы», «Электрон тәмәке һәм аның зарары» дигән темаларга класстан тыш чаралар үткәрелә. Бу чаралар, тәрбияви максатларга нигезләнеп, һәрдаим үтеп бара.

Шулай ук, яшьүсмерләр арасында хокук бозуларны кисәтүдә “Әхлак дәресләре”, “Мөслим кызы, Мөслим егете”, “Тормыш дәресләре” муниципаль проектларының нәтиҗәләре бар. Участок һәм балигъ булмаган балалар белән эшләүче инспекторлар белән очрашулар оештырабыз. Укучылар белән Өлкәннәр көнендә аларга ярдәм оештырдык. Шуны билгеләп үтәргә кирәк: мондый отрядлар оештыру һәм аларның эшчәнлеге укучыларда хокукый культура, милли үзаң, патриотизм һәм Ватанга мәхәббәт хисе формалаштыруга булышлык итә. Бу – хокук саклау органнары эшчәнлегенә карата яхшы мөнәсәбәт тудыра, чөнки эчке эшләр хезмәткәрләренең авыр һәм катлаулы эшенә кузаллау булдыра. Ахыр чиктә мондый чаралар укучыларның гражданлык, социаль активлыгын һәм физик әзерлек дәрәҗәләрен арттыра.

Әңгәмәгез өчен рәхмәт!

***Әңгәмәне үткәрде:***
***Айгильдина Зарина***

## САУЛЫКНЫ САТЫП АЛЫП БУЛМЫЙ


### Электрон сигаретлар зарары

*Электрон сигарет…* Яшьләр электрон сигарет тартуны кулай күрә, мәктәп укучылары арасында да тартучылар бар, хәтта үсмер кызлар да мавыга.

Тәмәке тартканда агулы һәм кайнар һава бүленеп чыга. Биредә салкын тәтен ингаляция формасында сулана. Ис килми, тешләр саргаймый. Өстәмә тәмләткечләр белән баетылган. Бар да уйланылган, зарарсыз кебек. Әйе, кебек!

Тәмәке төтене булмау никотин куллану дозасын арттыра, кеше күпме тартканын да чамаламый. Сыекча тышына язылган никотин күләме еш кына чынбарлыкка туры да килми. Ә дозаны арттыру нерв системасы параличына, хәтта үлемгә китерергә мөмкин. Никотин парлары тарткан урында стенага, тәрәзәгә, җиһазларга утыра. Электрон сигарет сату да шул ук наркотиклар сатуның бер ысулы. Составында психоактив матдәләр. Төп матдә - никотин алкалоиды. Үзәк нерв системасын ярсыта. Һәр төр психоактив матдә куллану башта гадәткә керә, куллана-куллана бәйлелек барлыкка килә – кеше хроник авыруга әйләнә. Тәмәкеме, хәмерме, наркотикмы, һәр очракта да авыруга әйләнү этаплары бер аның. Симптомнар да охшаш. Беренчесе - башта кечкенә доза кабул итү. Акрынлап доза арта. Куллану ешая. Икенче билге – организмның каршы тору сәләте кими. Өченчесе - кулланмагач, кеше авыр тойгылар кичерә башлый. Традицион тәмәкене сыекчага әйләндереп, аның пары белән сулаганнан берни үзгәрми.

Яшүсмерләр спайс, электрон тәмәке, кальян тартуны яшерен башкаралар, бәйлелек барлыкка килгәндә балигълык яшенә кергән булалар... Бәйлелек этапларыннын соң, психоз, шизофрения, психик авырулар барлыкка килгән авыр очраклар кабатланып тора. Кешенең психикасы зәгыйфьләнә. Шизофрения, мания, галлюцинация, паранойя кебек психик үзгәрешләр бик тиз барлыкка килә. Гадәттә, авыруны дәвалау һәр очракта да бик авыр. Укучылар тәмәке тартуның ялган ихтыяҗ икәнлегенә төшенергә тиешләр.



## УКУЧЫЛАР ИҖАТЫ

### Каен кызы.
### *(экологик әкият)*



Бер бик матур урман читендә яшәгән зифа буйлы Каен кызы. Аның күршесе булып Нарат үскән. Ул Каен кызының матурлыгына иртәдән кичкә кадәр сокланган. Нарат сылукайны көзге яңгырлар-дан ышыкласа, кыш көне ачы салкын җилләрдән саклаган. Каен кызы Наратны мәрхәмәтле булуы өчен бик яраткан, хөрмәт иткән. Алар мәңгелек дуслар булганнар.

Кышкы йокыдан соң, матур язлар килә. Барлык табигать тирән сулыш алып уяна башлый. Менә шушы гүзәл чорда Нарат дусты өчен борчыла башлый, чөнки кешеләр бу вакытта каен суы эчәргә ярата.

Бу язны да искәрмә ясамадылар, каен суына агылдылар. Наратның зифа буйлы күршесенә җәрәхәт ясадылар. Кешеләрнең кансызлыгына аның ачуы килде, йөрәге әрнеде...Тик бөтен кеше дә начар түгел икән!?

Кояшлы матур язгы көннәрнең берсендә мәктәп укучылары урманга табигать үзгәрешләрен күзәтергә килделәр. Каен кызы янынnан узганда, Алсу исемле кыз кычкырып елап җибәрде. Укытучы абый куркып, кыз янына килде. Ә Алсу бер сүз әйтә алмый, елый да елый, үзе каенга күрсәтә. Каен кызы да күз яшьләре түгә иде. Укытучы абый барысын да аңлап алды. Ул үзенең укучыларына Каен кызының хәлләре ни өчен начар икәнен аңлатты. Аңа ярдәм кирәклеген әйтте. Моны күзәтеп торган Нарат бик сөенде, чөнки дөньяда яхшы кешеләр бар икәненә инанды.

Укытучы малайлар белән сынган ботаклардан чөйләр ясадылар. Каен кызының күз яшьләре аккан тишекләрне шул агач чөйләр белән томалап куйдылар. Бераздан каен суы агудан туктады.

Каенга мондый яралар ясасаң, ул бик тиз корый. Әгәр инде суны аласың икән, ул яралы җирне акмаслык итеп капларга кирәк. Менә шушылар турында укытучы укучыларына сөйләде.

Бу минутта Нарат Каен дусты өчен бик нык сөенә иде.

***Насирова Мәрьям,***
***6 нчы в сыйныфы укучысы***

### Кышкы сихри табигать



Кояш нурларына җемелдәшеп, җир өстенә талгын гына тәңкә карлар ява.

Йокыга талган урман-кырларны, тау-үзәннәрне каплый кар бөртекләре. Кышкы тынлыкта оеп, морҗаларыннан салмак кына төтеннәр бөркеп утырган өйләрнең түбәләренә дә бүрек булып төшә алар. Әйтерсең лә, юмарт Кыш бабай, өшемәсен-туңмасын, дип, болын-тугайлар өстенә ап-ак мамык юрган ябып йөри. Һәм, гүя, һәр тараф нурлы бер әкияти дөньяга әйләнә. Син мәктәпкә барганда яки өлкәннәргә булышканда, шугалакта уйнаганда яисә чаңгы тагып урман буйларына килеп чыкканда, агачларның томанга өретелгәндәй көмеш бәсләренә карап сокланасың. Туган җирнең һәр төшендә бер яңалык, матурлык күреп, елмаеп куясың. Күңелгә әйтеп бетергесез шатлык, куаныч тула да, килер бәхетләр,данлы вакыйгалар турында уйлый башлыйсың.

Шулвакыт кайдадыр бомбалар шартлый. Өйләр, балалар бакчалары, мәктәпләр җимерелә, табигать анабыз биргән матурлыкның юкка чыгуы искә төшкәч бик тә, бик тә ямансу булып китә. Сугышлар бетсен, барлык кешеләр дә тирә-юнебездәге матурлыкка сокланып карасын!

***Хәйруллина Диләрә,***
***6 нчы в сыйныфы укучысы***

### Кыш бабай



Шыгыр-шыгыр чың-чың-чың,
Буранны ерып-ерып,
Атларда чаба-чаба,
Кыш бабай үтеп бара.
Кемнәр аңа хат яза,
Барсына бүләк ала.
Яңа елда балаларга
Күчтәнәчләр тарата.
Ә балалар Кыш бабайга
Шөгыльләрен күрсәтә.
Мин дә менә шигырь язам
Бабыкайга бүләккә.

***Ханнанова Алинә,***
***9 нчы а сыйныфы укучысы***

ТЫЛСЫМ+
Гыйнвар, 2023 нче ел
***Мөслим гимназиясе укучылары газетасы***

**Баш мөхәррир:** Солтанова Г.М.
**Техник редактор:** Кадыйрова А.Р.
**Мөхәррир:** Минһаҗева Камилә
**Корректорлар:** Минһаҗева Диләрә
**Корреспондентлар:** Айгельдина Зарина, Солтанова Алия

**Дизайнер:** Садриев Илназ
**Компьютерда җыючылар:** Латыпов Илназ, Хаертдинов Ранис
**Гамәлгә куючы:** Мөслим гимназиясе укучылар иҗат үзәге
**Адрес:** Мөслим, Кооператив урамы, 170а
**Сайт:** https://edu.tatar.ru/muslum/muslumgym
**Электрон адрес:** tilsim.gimnazia@yandex.ru
**Тираж**: 100